**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«25» октябрь, 2019 № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Кыр Буасы авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә алып барырга.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
   а) авыл җирлеге территориясен төзеклэнлэндерү:
   - авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;
   б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
   - су үткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;
   в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:
   - авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;
3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Мәлки авыл җирлеге Башлыгы Ф.П.Поляков